**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 27.07.2020** **№ 580**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 9 февралендәге 368 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне оештыру һәм үткәрүнең һәм муниципаль хокукый актлары проектларына экспертиза ясау Тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2014 елның 07 мартындагы 14-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» ТР Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, **КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 9 февралендәге 368 нче номерлы «Биектау муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне оештыру һәм үткәрүнең һәм муниципаль хокукый актлары проектларына экспертиза ясау Тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның 2 нче пунктында җәяләр эчендәге «(С.М.Мингазов)» сүзен төшереп калдырырга;

2) Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне оештыру һәм үткәрү һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау Тәртибендә, 1.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.11. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрдән тыш бәяләнергә мөмкин:

1) Биектау муниципаль районы Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы норматив хокукый актлары проектлары;

2) Биектау муниципаль районы Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актлары проектлары».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты эшләре белән идарә итүчесе Г.Ф. Сабировага йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин